**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«11» 12 2024 ел Яр Чаллы ш. № 5524

ТР Тукай муниципаль районы «Калмаш урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставының 29 статьясы 20 пункты, «Муниципаль мәгариф оешмалары хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 10 январендәге 4 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. ТР Тукай муниципаль районы «Калмаш урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 1 кушымта нигезендә расларга.
2. ТР Тукай муниципаль районы «Калмаш урта белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәт бәяләре прейскурантына кертелгән хезмәтләр бәясе хисабын 2 кушымта нигезендә расларга.
3. Карарның гамәлдә булуы 2024 елның 01 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарны ТР Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 12 октябрендәге 3438 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «ТР Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы вазыйфаларын башкаручы Э.Р. Низамиевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы К.Р. Нәҗмиев

Муниципаль район Башкарма комитетының 2024 елның «11» 12 5524 номерлы карарына 1 кушымта

2024 елның 1 октябреннән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Калмаш урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ буенча түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бер тәрбияләнүчегә бәяләр прейскуранты

| № | Хезмәтнең исеме | Хезмәт бәясе (сум) | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| 1 | «Мәктәпкә әзерләнү» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 2 | «Рус грамматикасы» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |
| 3 | «Математиканың сайланган мәсьәләләре» | 400,00 | Айга 1 тапкыр (4 дәрес) |

ТР Тукай муниципаль районы «Калмаш урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ директоры ____________ В.Х. Кашапова

«Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» МБУ җитәкчесе урынбасары ____________ Р.Р. Йосыпова

ТР Тукай муниципаль районы «Калмаш урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГББУ тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүгә бәяләр прейскурантына кушымта

1. **«Мәктәпкә әзерләнү»**- мәктәпкәчә яшьтәге балаларны яңа белем бирү шартларына уңышлы яраклаштыруга һәм бер белем бирү баскычыннан икенчесенә гуманлы (уңайлы) күчү шартларын булдыруга юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 54 кв.м., балалар саны - 20.

2. **«Рус грамматикасы»**- рус теленең байлыгын өйрәнүгә, аның күп кенә «серләрен» ачуга, рус теле үз эченә алган зур танып белү байлыгын кулланырга һәм аны сөйләм практикасында кулланырга өйрәтүгә юнәлтелгән.

Әлеге хезмәт 6 яшьтән алып 7 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 54 кв.м., балалар саны - 20.

3. **«Математиканың сайланган мәсьәләләре»** - предметка тотрыклы кызыксыну тудыруга һәм ярдәм итүгә, логик фикерләүне һәм математик сөйләмне үстерүгә юнәлдерелгән.

Әлеге хезмәт 14 яшьтән 15 яшькә кадәрге балаларга, кабинетның мәйданы 54 кв.м., балалар саны - 13.

ТР Тукай муниципаль районы
«Калмаш урта гомуми белем бирү
мәктәбе» МБГББУ директоры ________________ В.Х. Кашапова

ОГРН 1021601371516 "КАЛМАШСКАЯ СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА" ДЛЯ ДОКУМЕНТОВ ИНН 1639018980